КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 сентябрь г.Казань № 820

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советын оештыру турында» 2018 ел, 19 апрель, 269 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советын оештыру турында» 2018 ел, 19 апрель, 269 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 август, 676 нчы; 2020 ел, 17 февраль, 117 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Яраштыру советы составыннан К.И.Ваһаповны, Д.Г.Калинкинны чыгарырга;

Яраштыру советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Гыйльфан улы Гафаровны (килешү буенча);

«Алкоторг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры Андрей Анатольевич Феоктистовны (килешү буенча);

Тимур Җәмил улы Баймуллин вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«X5 GROUP» компаниясенең «Идел» макротөбәгендә дәүләт органнары белән эшләү юнәлеше җитәкчесе (килешү буенча)»;

Любовь Николаевна Шәйхетдинова вазыйфасы исемендә «җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы» сүзләрен «җитәкчесе» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин